**СОВЕТ НАРМОСКОГО ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422630 ,РТ, Лаишевский район,
село нармонка, ул.Молодежная, д.12а
Тел: 8 (84378) 4-62-24
Факс: 8 (84378) 4-62-24

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН НАРМОНКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422610 Лаеш районы,Нармонка авылы
Яшьлэр ур., 12 а анчейорт
Тел: 8 (84378) 4-62-24
Факс: 8 (84378) 4-62-24

**2020 елның 12 феврале** **1 номерлы**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты хакында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы һәм “Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында” 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Нармонка авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ**:**

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге Советы карары (алга таба - Карар) (1 нче кушымта) проектын хупларга.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.
3. Расларга:

– «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге советы карары проекты буенча гражданнарны исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибе (2 нче кушымта);

- «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе (3 нче кушымта).

4. Билгеләргә:

4.1. Гавами тыңлаулар уздыру датасы - 2020 елның 03 марты.

4.2. Гавами тыңлаулар уздыру вакыты – 14-00 сәгатьтә.

4.3. Үткәрү урыны: ТР, Лаеш муниципаль районы, Нармонка авыл җирлеге, Нармонка авылы, Габишев ур., 6Б йорт, мәдәният йорты адресы буенча.

5. Әлеге карарны «Кама ягы» район газетасында, махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru.веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Советы аппаратына һәм Башкарма комитетына ачык тыңлаулар үткәрүне, күрсәтелгән карар проекты буенча, гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

7. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге советына, гавами тыңлауларда әйтелгән һәм аның буенча фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге советы утырышына карауга кертергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Нармонка авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Л.Д.Стерякова**

Татарстан Республикасы Лаеш
муниципаль районының
Нармонка авыл җирлеге
Советының 2020 елның
1 номерлы карарына
1 нче кушымта .

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр**

1. 5 статьяның 1 пунктындагы 14 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«14) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортировкалау эшчәнлеген оештыруда катнашу;».

2. 6 статьяның 1 пунктындагы 13 пунктчасында «хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау чаралары» сүзләрен «йорт хуҗалары булмаган хайваннар белән эш итү эшчәнлеген» сүзләренә алмаштырырга.».

3.1 статьяга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 6.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. Депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затның вәкаләтләре «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законның 40 статьясына үзгәрешләр кертү хакында «2009 елның 26 июлендәге 228-ФЗ номерлы Федераль законда башкача каралмаган булса «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла.

б) 6.3 пунктта «Нармонка авыл җирлеге советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать итә» сүзләрен «депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең

сайланулы вазыйфаи заты яисә күрсәтелгән затларга карата башка җаваплылык чарасы куллану турында гариза белән мөрәҗәгать итә» сүзләренә алмаштырырга.

4.34 статьяның 21 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

5. 50 статьяның 2 пунктындагы 14 абзацында «хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау чаралары» сүзләрен «йорт хуҗалары булмаган хайваннар белән эш итү эшчәнлеге» сүзләренә алмаштырырга.».

6. 86 статьяга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль финанс контроле бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан физик затларга бүтән түләүләр буенча гавами норматив йөкләмәләрне һәм йөкләмәләрне билгели торган хокукый актлар нигезләмәләрен, шулай ук муниципальара контрактлар, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.»;

б )2 пунктта «бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«3. Эчке муниципаль финанс контроле Федераль казначылыкның, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының финанс-бюджет палатасының контроль эшчәнлеге булып тора.».

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Нармонка авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Л.Д.Стерякова**

Татарстан Республикасы Лаеш
муниципаль районының
Нармонка авыл җирлеге
Советының 2020 елның
1 номерлы карарына
2 нче кушымта .

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге "муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында" карары проекты буенча гражданнар тәкъимнәрен исәпкә алу һәм аның турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге "муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында" карары проекты буенча гражданнар тәкъимнәрен исәпкә алу һәм аның турында фикер алышуда гражданнарның катнашуы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча язма формада кертелә: Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Нармонка авылы, Яшьләр ур., 12 А.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән бер ай эчендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Халык алдындагы тыңлауларда катнашу хокукына гаризалар шәхсән яисә почта аша, конвертта «Уставка үзгәрешләр кертү турында фикер алышу» тамгасы белән, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Нармонка авылы, Яшьләр ур., 12 А адресы буенча бирелә.

Гаризалар гавами тыңлаулар уздыру датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча эш көннәрендә 8 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Нармонка авыл җирлеге**
**Советы рәисе Л.Д.Стерякова**

Татарстан Республикасы Лаеш
муниципаль районының
Нармонка авыл җирлеге
Советының 2020 елның
1 номерлы карарына
3 нче кушымта .

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге "муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында" карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге "муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында" карары проекты буенча гавами тыңлаулар (алга таба - гавами тыңлаулар) «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә уздырыла».

2. Гавами тыңлауларда җирле үзидарә органнары һәм аларның вәкилләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, гавами тыңлаулар экспертлары, гавами тыңлаулар үткәрү буенча оештыру комитеты әгъзалары, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге халкы һәм гражданнар катнаша.

3. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланырга 30 минут кала башлана.

4. Гавами тыңлауларда рәислек итүче булып оештыру комитеты рәисе тора.

5. Халык тыңлаулары рәиснең кереш сүзе белән ачыла, ул катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлаулар уздыру тәртибе турында хәбәр итә.

6. Оештыру комитеты секретаре гавами тыңлаулар протоколын алып бара.

7. Төп нотык белән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге советы депутаты чыгыш ясый.

8. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашучылар гариза бирү вакытына бәйле рәвештә чиратлылык тәртибендә үз тәкъдимнәрен аргументацияләү өчен чакырыла.

9. Гавами тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел..

10. гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга утырыш тәмамлангач рәис рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

11. Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны туктатырга һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

12. Гавами тыңлаулар уздырганда тәртип саклау гавами тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора..

13. Халык алдында тыңлаулар уздыру тәртибен бозган очракта, рәис аларны утырыш залыннан алуны таләп итәргә хокуклы.

14. Гавами тыңлауларда катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре секретарьга язма рәвештә бирелә һәм гавами тыңлаулар беркетмәсенә кушып бирелә. Гавами тыңлаулар беркетмәсенә рәислек итүче һәм сәркатип имза сала.

15. Гавами тыңлаулар беркетмәсе нигезендә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә төзелә

16. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә халыкка игълан ителергә тиеш.

17. гавами тыңлаулар уздыруны оештыру һәм матди-техник тәэмин итү оештыру комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Нармонка авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Л.Д.Стерякова**